| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 29.09.2021 г. Казань № 158-5/соц-2021

Гомер өчен кирәкле һәм аеруча мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын җитештерүчеләр тарафыннан билгеләнгән фактик сатып җибәрү бәяләренә күмәртәләп сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен һәм ваклап сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен билгеләү турында

«Дару чараларын әйләнештә йөртү турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы, «Гомер өчен кирәкле һәм аеруча мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2010 елның 29 октябрендәге 865 номерлы, «Гомер өчен кирәкле һәм аеруча мөһим дару чараларына бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салуны камилләштерү турында» 2009 елның 8 августындагы 654 номерлы карарлары, Россия Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимият органнары тарафыннан гомер өчен кирәкле һәм аеруча мөһим дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына дару препаратларын җитештерүчеләр билгеләгән фактик сатып җибәрү бәяләренә күмәртәләп сатуда чик дәрәҗә өстәмә һәм ваклап сатуда чик дәрәҗә өстәмә бәяләр билгеләү методикасын раслау турында» 2020 елның 9 сентябрендәге 820/20 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, гомер өчен кирәкле һәм аеруча мөһим дару препаратлары исемлегенә (алга таба – ГӨКҺАӘДП) кертелгән дару препаратларына дару препаратлары җитештерүчеләр тарафыннан билгеләнгән фактик сатып җибәрү бәяләренә күмәртәләп сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен һәм ваклап сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен билгеләргә.

2. Түбәндәге боерыкларны үз көчен югалткан дип танырга:

«Гомер өчен кирәкле һәм аеруча мөһим булган препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын җитештерүчеләр тарафыннан билгеләнгән фактик сатып җибәрү бәяләренә кумәртәләп сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен һәм ваклап сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен билгеләү турында» 19.02.2010 №8-1/соц Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитеты карарын;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең «Дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге эшләнмәләрнең бәяләренә кумәртәләп сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен һәм ваклап сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен билгеләү турында» 2010 елның 19 февралендәге 8-1/соц номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 21 августындагы 8-3/соц номерлы Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе карарын;

«Гомер өчен кирәкле һәм мөһим булган дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын җитештерүчеләр тарафыннан билгеләнгән чынлыкта сатып җибәрү бәяләренә кумәртәләп сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен һәм ваклап сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләрен билгеләү турында» 19.02.2010 №8-1/соц Татарстан Республикасы Тарифлар буенча комитеты карарына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 28 июлендәге 128-4/соц-2021 номерлы Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты карарын.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 эш көне узгач гамәлгә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
29.09.2021 № 158-5/соц-2021
карарына кушымта

# ГӨКҺАӘДП исемлегенә кертелгән дару препаратларына дару препаратлары җитештерүчеләр тарафыннан билгеләнгән фактик сатып җибәрү бәяләренә күмәртәләп сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләре һәм ваклап сату өстәмәләренең чик дәрәҗәләре

| Җитештерүчедән җибәрелә торган фактик бәя (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) | Җитештерүчеләрдән фактик җибәрелә торган бәяләргә чик дәрәҗә өстәмә бәя күләмнәре (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча), % | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күмәртәләп | | ваклап | |
| | ГӨКҺАӘДП, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр исемлегенә кертелгән ГКӘДП тыш* | наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр исемлегенә кертелгән ГӨКҺАӘДП* | ГӨКҺАӘДП, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр исемлегенә кертелгән ГКӘДП тыш* | наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр исемлегенә кертелгән ГӨКҺАӘДП* |
| 100 сумга кадәр (иң күбе) | 15 | 23 | 30 | 30 |
| 100 сумнан кыйммәтрәк һәм 500 сумга кадәр (иң күбе) | 13 | 15 | 25 | 30 |
| 500 сумнан кыйммәтрәк | 10 | 13 | 19 | 30 |

* Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1998 елның 30 июнендәге 681 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә әйләнеше чикләнгән һәм үзләренә карата Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә контрольлек чаралары билгеләнә торган наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр исемлеге (II исемлек) һәм Россия Федерациясендә әйләнеше чикләнгән һәм үзләренә карата Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре нигезендә контрольлек чараларының кайберләрен төшереп калдыру рөхсәт ителә торган психотроп матдәләр исемлеге (III исемлек)

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге